Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге Дружба авылы
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

« 14» ноябрь 2019 ел. № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2019 елның 14 ноябрендә «2020 елда һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән граждданнар җыены беркетмәсе төзелде., Ләке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән (1 төркем инвалид, ялгыз карт гражданнар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш), һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү турында Карар кабул ителде:

- Дружба авылы зиратын коймалау буенча төзелеш материаллары сатып алу һәм эшләр өчен түләү ;

- Ләке авыл җирлеге Үзәк Сабантуена, Питрау көнгә бүләкләр алу.

“ӘЙЕ” «ЮК».

14.11.2019 елдагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә халык җыенында катнашкан 37 кеше, 30 кеше тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 26 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге, Сарман муниципаль районы Дружба авылында узган халык җыенын халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Ләке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2020 елда үзара салым акчаларын кертүгә килешәсезме?:

- Дружба авылы зиратын коймалау буенча төзелеш материаллары сатып алу һәм эшләр өчен түләү ;

- Ләке авыл җирлеге Үзәк Сабантуена, Питрау көнгә бүләкләр алу.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru , Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http / / sarmanovo. tatar. ru. һәм Дружба авылы, Лесная ур., 2А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.И. Шәрипова